РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» июля 2023 ел г. Альметьевск № 2539

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләме турында» 2023 елның 27 июнендәге 1973 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 һәм 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта хезмәт күрсәтүләр һәм идарә итү, тоту һәм ремонт эшләре башкарылган очракта, торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен тиешле сыйфатсыз һәм (яисә) билгеләнгән дәвамлылыктан артып китүче өзеклекләр белән үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләме турында» 2023 елның 27 июнендәге 1973 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче кушымтаның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә.

Зак. № 305-2000

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10. | Җылылык алмаштыру җайланмалары белән җиһазландырылган салкын һәм кайнар су белән тәэмин итүнең йорт эчендәге су үткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт | сум/кв. м | 3,17 |

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2023 елның 01 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов